СОВЕТ РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РУС ӘҖИЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**02 апреля 2024 года**

с.Русское
Азелеево

**КАРАР**
**№ 155**

Рус Әҗиле авыл җирлеге Советының 2021 елның 13 июлендәге № 38 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Рус Әҗиле авыл җирлеге Советының 2022 елның 17 августында 77 номерлы, 2023 елның 16 августындагы 128 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә 2021 елның 13 июлендәге 38 номерлы Рус Әҗиле авыл җирлеге советы карары белән расланган (2022 елның 17 августындагы 77 номерлы, 2023 елның 16 августындагы 128 номерлы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Җир кишәрлекләрен тоту» бүлегенең 1 пунктындагы унөченче абзацында «, тимер юллар» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) тоту» 4 бүлегенең 7 пунктында «, иҗтимагый (тимер юл) транспортының контакт челтәре тирәкләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) тоту» 4 бүлегенең 8 пунктындагы беренче абзацында «, җәмәгать (тимер юл) транспортының контакт челтәре терәге» сүзләрен;

1.4. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) тоту» 4 бүлегенең 9 пунктында «һәм җәмәгать (тимер юл) транспортының контакт челтәре терәкләрендә,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. 4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1йорт (җирлек администрациясе бинасы), Карәшәм авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Г.Ф.Семахина**